Республика Татарстан
руководитель Исполнительного
комитета Пестречинского
муниципального района 422770,
с. Пестрецы, ул. Советская, 18

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы башкарма
комитеты җитәкчесе 422770, Питрәч
авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«____»____________20__ ел №______

**"2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау һәм кешеләрнең су объектларында иминлеген тәэмин итү муниципаль программасын раслау турында" 2019 ел, 29 гыйнвар, 135 нче карары**

**"2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау һәм кешеләрнең су объектларында иминлеген тәэмин итү муниципаль программасын раслау турында"**

"Татарстан Республикасы дәүләт программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен һәм Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеген раслау турында» 2012 елның 31 декабрендәге 1199 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын үтәү йөзеннән Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. «2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау һәм кешеләрнең су объектларында иминлеген тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында, 2011 ел, 10 август, 672 нче карары (кушымта итеп бирелә).
2. Питрәч муниципаль районы муниципаль учреждениеләренә, Питрәч муниципаль районы бюджетын формалаштырганда һәм үтәүне оештырганда программа нигезләмәләренә таянып эш итәргә.
3. Ел саен чираттагы финанс елына район бюджетын формалаштырганда, әлеге максатларга Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы бюджетыннан җибәрелә торган мөмкинлекләрне исәпкә алып һәм акчалар чикләрендә Программа чараларын тормышка ашыруга акча каралырга тиеш.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе А. В. Хәбибуллин